# Татар сувенирлары кемгә кирәк?

Көннәрнең берендә Казан урамында шагыйрь, рәссам һәм сынчы Хәмит Латыйпов белән очраштык. Аның йөзе болытлы көндәй сүрән иде.

— Туймазыга кире кайтып китәргә булдым әле, туган, — диде ул хәл-әхвәл сорашкач.

Хәер, биредә бераз чигенеш ясап, укучыны аның үзе белән дә берникадәр таныштыру урынлы булыр. Рәссам озак еллар дәвамында Башкортстанның Туймазы шәһәрендә иҗат итеп яшәде. Ул — сәнгатьнең милли керамика һәм агачка уеп ясау өлкәсендә эшли торган һөнәрмәнд. Бу өлкәдә үз мәктәбен тудырган иҗатчы. Аның эшләре күптөрле гомум һәм шәхси күргәзмәләрдә катнашкан. Татарстан дәүләт музеена, Казан милли-мәдәни үзәгенә куелган. Туймазы шәһәре исә аның пастель техникасында язылган кырыктан артык уникаль картинасын сатып алган. Чит илләрдә дә аның иҗатын яхшы беләләр. Ул ясаган килен сандыкларын заманында хәтта ЮНЕСКОның Парижда оештырылган күргәзмәсенә дә алып барган иделәр. Аның иҗаты хакында, аерым алганда, татарның танылган сәнгать белгече Гүзәл Вәлиева-Сөләйманованың "Декоративное искусство Татарстана" дигән саллы җыентыгында да бик атрафлы итеп язылган. Татар матбугаты да аңа беркадәр игътибарлы булды кө-

үюның үзенчәлекле алымнарын сурәттән сурәткә камилләштерә барган, композицион бөтенлеккә ирешкән рәссам! Сюжет төрлелеге дә шаккаттыра, сокландыра. Сак-Сок, карурман, әкияти кошлар, Елан-Патша, Су анасы, Шүрәле, Курайчы малай, Кол Шәриф мәчете, Сөембикә манарасы... Фольклорга да, халкыбызның чын-асыл яшәешенә дә нигезләнгән төрле-төрле сюжетлар, вариантлар. Менә, мәсәлән, Сөембикә манарасы янынннан көянтәсенә чиләкләрен асып чишмәгә су алырга төшеп килүче кыз. Әйе, боларны аңлар өчен, бәгырен аша үткәрү өчен татар булуың да кирәк шул! Пас-



портта гына, исем-фамилиядә генә түгел! Абстракт-авангард юнәлешендәге сурәтләре дә бар. Күзгә, акылга үтеп керә, әсир итә.

Мәгълүм ки, Африканың

журналында (2000 нче ел, 12 нче сан) аның иҗатына соклануымны белдергән идем.

Ни булды икән соң рәссамга? Нигә ул — моннан берничә ел элек башкалабызга зур иҗади хыяллар белән кайткан рәссам (әйе, һәр татар Казанга кайта дибез бит!): "Казанга кирәгем чыкмады", — ди? Югыйсә, ул биредә җаны-тәне белән рухланып, канатланып иҗат итә башлаган иде. Башкалабызның 1000 еллык бәйрәменә багышлап аның сувенир эскизлары иҗат итүе дә мәгълүм.

— Әле узган елда гына да агачка уеп эшләнә торган дүрт йөз декоратив сувенир тәлинкәләр эскизы эшләдем, — ди ул. — Әмма аларны сувенир итеп ясап чыгару өчен махсус цех кирәк.

— Соң, Хәмит абый, нәкъ менә шушы эшләр белән шөгыльләнүче махсус комиссияләр, комитетлар, әллә нинди оешмалар ачтылар лабаса! Республика күләмендә Казанның 1000 еллыгына сувенирлар ясау буенча олы-олы киңәшмәләр, утырышлар гел үткәрелеп тора, — дим.

— Барысына да йөреп чыктым. Эшләремне күрсәттем. Нури Мостафаевта да булдым. Әмма миңа конкрет ярдәм итүче генә юк. Берничә станок җиһаз да цех өчен урын гына кирәк югыйсә. Эскизларны сувенир итеп гамәлгә ашырырдай осталарым да бар. Сүз күп, ә эш юк.

Хәмит Латыйпов бу дүрт йөз эскизын, алны-ялны белмичә, узган ел дәвамында ясаган. Мәгълүм ки, елда —өч йөз алтмыш биш көн... Хәзер рәссамның мондый сурәт-эскизлары унмеңгә җитеп килә икән инде. Менә кайда ул куәтле иҗат чишмәсе! Әмма... агачка уелырга тиешле сурәтнең кәгазьдә генә катып калган мәле... Өтергә белән

га танылган. Соң, әлләни ерак китмичә, үзебезнең урыс осталарын гына алыйк. Гжель, федоскино, хохлома дөньякүләм шөһрәткә иреште. Нигә дисезме? Дәүләт ярдәме нәтиҗәсендә! Әмма дә нигә менә татар сувенирларын бар итәргә алынып, рәсемнәрендә борынгы болгарыбыздан, шанлы татар тарихыбыздан саркып торган чалымнарны күрсәтә алган рәссамга ярдәм итәргә теләми икән дәүләтебез? Казанда сувенирлар җитештерүче "Батыр" атлы фабрика бар иде. Кайда ул? Олы-олы киңәшмәләрдә сөйләнгән сүзләр дә юкка чыга тора. Сүз белән гамәл арасында бездә, ни аяныч, гаять зур упкын ята шул... Ә инде сувенир өчен рәсми рәвештә җавап тотарга тиешле түрәләрнең үз эшенә битараф каравы, минемчә, милләт каршында җинаятькә тиң.

Казанның 1000 еллыгы да инде, кем әйтмешли, борын төбендә. Олуг бәйрәмебезгә бөтен дөньядан җыелган мәртәбәле кунаклар алдында африка маймылы белән урыс гжеленең уйнаштан туган сувенирлары пәйда булса һич кенә дә гаҗәпләнә торган түгел. Татар моннан да кәттәрәк әкәмәтләргә дучар булып, каешланып беткән инде ул.

Минем үземне бер әйбер сискәндерде. Бер деталь! Хәмит Латыйповның алда аталган бер эскизында Сөембикә манарасы яныннан кыз бала чишмәгә су алырга төшеп килә. Уйлап карагыз әле, җәмәгать: бүгенге көндә, шөкер, манарабыз да, кызларыбыз да бар. Тик менә чишмәбез генә югалган ахры. Кайчандыр, моннан ничә гасырлар элек камалыштагы фидаиләрнең сусавын баскан чишмәбез генә югалган...

**Марат ЗАКИР.**